ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 45 12.03.2021 ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының
«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт
вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү
тәртибе турында Нигезләмә хакында»
15.12.2020, № 23 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрүне тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 02.03.2007, №25-ФЗ Федераль законның 17 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 20 статьясы нигезендә, Аксубай муниципаль районы Советы
КАРАР ИТТЕ:
1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләп биләүгә конкурс үткәрү тәртибенә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмә хакында» 15.12.2020, № 23 карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1). 9 пунктның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) кирәкле һөнәри белем, квалификацияне һәм эш стажын раслаучы документлар:
хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт (эш) эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш) яисә гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслаучы башка документлар;
белем бирү һәм квалификация турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яисә тапшыруны раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗә бирү, гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре;».
2). 9 пунктның 7 өлешен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы сайтында интернет челтәрендә (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга
3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы Башлыгы,

Совет Рәисе К.К.Гилманов